КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1278

Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 92 статьясы, "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 393 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин